**ТАТАРСТАН Республикасы**
**Аксубай муниципальрайоны**
**муниципаль беремлеге**
**Емелькино авылы**

**Республика ТАТАРСТАН**
**Аксубаевский**
**муниципальный район**
**муниципальное образование**
**село Емелькино**

**Совет Емелькинского сельского поселения**

423056, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район, село Емелькино, ул. Центральная д.16
Тел.(8-84344-4-76-22) ОГРН 1021605364980, ОКПО 94318599,ИНН/КПП 1603000796/160301001

КАРАР

№ 1 24 ноябрь 2024 ел

«Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге
Яңа Чуаш Адам авылында гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында"

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 09 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Емелькино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә

Карар бирәм:

1. 2024 елның 04 декабрьендә 14 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча авыл клубы бинасында билгеләргә: ТР, Аксубай районы, Яңа Чуваш Адам авылы, .Пушкин ур., 19 йорт Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлегенең Яңа Чуваш Адам авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:
Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлегенең Яңа Чуаш Адам авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, хәрби хезмәткә чакырылган, өлешчә мобилизацияләнгән һәм.контракт буенча хәрби хезмәткәрләрдән ,аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, , 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә,алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1.Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кыш көне карап тоту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, ягулык - майлау материаллары сатып алу, торак пункт чикләрендә вак таш белән капланган юл өслеген урнаштыру ( вак таш, ВКПС сатып алу, эшләр өчен түләү-грунт күтәрү, вак таш, ВКПС сибү, сатып алу) сууткәргеч торбалар), торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау (вак таш, шпс сатып алу, эшләр өчен түләү)

2.Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү, кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу - ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү)

- Урамнарны яктырту җайланмасы (торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен шартнамә буенча товарлар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;)

«РИЗА» "КАРШЫ" «ТЫЕЛЫП КАЛДЫМ»

3.Әлеге карарны Емелькино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/

Аксубай муниципаль районы
Емелькино авыл җирлеге башлыгы Н.И.Михайлова